ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САВАЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Центральная, д.11, с. Савалеево, Заинский район, 423537

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӘВӘЛӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк урамы, 11 нче йорт, Сәвәләй авылы, Зәй районы, 423537

Телефон/факс 62-3-47. Электронный адрес: Sav.Zai@tatar.ru,
сайт: http://zainsk.tatarstan.ru/rus/savaleevskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2019 ел № 22

**«Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чорында Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә урнашкан объектларның һәм торак пунктларның иминлеген тәэмин итү чаралары турында»**

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре вакытында Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә янгыннар чыгуны һәм аларда кешеләр үлүне кисәтү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законы, «Федераль дәүләт янгын күзәтчелеге турында» 2012 елның 12 апрелендәге 290 номерлы РФ Хөкүмәте карары, Зәй муниципаль районы «Сәвәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 47 статьясы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә объектларның һәм торак пунктларның Яңа ел һәм Раштуа чаралары үткәрүгә әзерлеген, шулай ук пиротехник эшләнмәләр куллану урыннарын тикшерү буенча ведомствоара комиссия төзергә һәм аның составын кушымта нигезендә расларга.

Ведомствоара комиссиягә:

- 2019 елның 20 декабренә кадәр объектларның һәм торак пунктларның Яңа ел һәм Раштуа чараларын үткәрүгә, шулай ук пиротехник эшләнмәләрне куллану урыннарының әзерлеген тикшерергә;
- тикшерү нәтиҗәләре буенча мәгълүматны Зәй муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр бүлегенә тапшырырга.

2. Тәкъдим итәргә:

3.1. Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждение һәм оешма җитәкчеләренә:

- 2019 елның 20 декабренә кадәр хезмәт коллективларында, шулай ук халык белән янгын куркынычсызлыгы чаралары турында өстәмә инструктажлар һәм әңгәмәләр үткәрергә;

- бәйрәм чаралары үткәрү планлаштырылган биналар һәм бүлмәләрдә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- бәйрәм чаралары үткәргәндә биналарда һәм бүлмәләрдә, шулай ук биналардан һәм корылмалардан 50 метрдан да якынрак урыннарда пиротехник эшләнмәләр куллануны тыярга;

- чараларны оештырганда һәм үткәргәндә кешеләрнең әлеге объектлар һәм биналар өчен билгеләнгән норматив саннан артып китүенә юл куймаска.

3.3. «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе, «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәдәни-күңел ачу учреждениеләре җитәкчеләренә:

- биналарда һәм бүлмәләрдә бәйрәм чараларын бары тик Зәй муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге белән килешеп кенә үткәрергә;

- чаралар үткәрү чорында тиешле эчке боерык (күрсәтмә) белән билгеләнгән җаваплы затларның кизү торуын оештырырга;

- янгын чыккан очракта кешеләрне тиз һәм куркынычсыз эвакуацияләү, шулай ук беренчел янгын сүндерү чаралары белән файдалану буенча өстәмә инструктажлар һәм өйрәнүләр үткәрергә;

- янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлмәгән биналарда һәм бүлмәләрдә чаралар үткәрүне тыярга;

- биналарны һәм бүлмәләрне бәйрәм аксессуарлары белән бизәгәндә янгын куркынычсызлыгы нормаларына һәм таләпләренә җавап бирә торган әйберләр генә кулланырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **П.С.Уразайкин**

Исп. Л.М.Соколова
62-3-47

Сәвәләй авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенең
2019 елның 09 гыйнварындагы
01 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә объектларның һәм торак пунктларның Яңа ел һәм Раштуа чараларын үткәрүгә әзерлеген, шулай ук пиротехник эшләнмәләр куллану урыннарын тикшерү буенча ведомствоара комиссия составы

| *№ п/п* | *Фамилиясе, исеме, атасының исеме* | *Вазыйфа* | *Контакт өчен телефоннары* | |
|---|---|---|---|---|
| | | | эшнеке | кәрәзле элемтә |
| 1 | Уразайкин Петр Сергеевич | Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы | 6-23-47 | 919-684-56-03 |
| 2 | Иванов Вадим Николаевич | Сәвәләй урта мәктәбе директоры | 6-23-35 | 903-318-17-35 |
| 3 | Бутяева Ольга Григорьевна | Сәвәләй мәдәният йорты директоры | 6-23-55 | 960-072-43-17 |
| 4 | Москова Елена Георгиевна | «Ромашка» балалар бакчасы мөдире | 6-23-35 | 960-072-98-59 |
| 5 | Абрамов Геннадий Павлович | «Зәй шикәре агрофирмасы» ҖЧҖнең Сәвәләй бүлекчәсе җитәкчесе | 6-23-49 | 919-639-09-19 |